**«Оста кулда һөнәр бар»**

3 А, Б, И сыйныфы тәрбиячеләре Гозәерова Лилия Наил кызы һәм Хәбибуллина Ләйсән Рәшид кызы «Оста кулда һөнәр бар» дигән исемле очрашу кичәсе уздырдылар. Чара әлеккеге өй күренеше һәм укучылар башкаруында сәхнәдә борынгы әби-бабаларыбызның көнкуреше, аларның кул эшләрен чагылдырган мизгелләр белән башланып китте. Әби үзенең яшь чагындагы чиккән сөлгеләрен, чабата, көянтә-чиләкләрен, тубәтәй, тәрәзә чаршауларын оныкларына күрсәтеп сөйли. Чабата биюе дә читтә калмый. Тальян гармунында өздереп уйнап җибәргән Булат күп тамашачыларның йөрәкләрен сискәндергәндер. Бәйрәмебезне кичәбезнең кунагы - Норма авылында яшәп, матур кул эшләре ясаучы Госман ага Хәсәншин дәвам итте. Ул укучыларга алып килгән сандык, шкатулка, беләзек һәм башка кул эшләре иҗаты белән таныштырды, аларны ясау өчен нинди мөмкинлекләр, теләк, вакыт кирәклеге турында сөйләде. Укучылар һәм дә без бик игьтибар белән күзәтеп, тыңлап бардык, кызыксындырган сорауларны бирдек. Кичәбез ахырында Госман агага теләкләребезне һәм олы рәхмәтебезне белдердек.

Бу кичә яки төрле чараларны уздырганда балаларда әхлаклылык, әдәплелек кебек сыйфатлар тәрбияләнә. Балалар ана телендә дөрес, матур итеп аралашырга өйрәнә. Татар халкының электән сакланып килгән бәйрәмнәрен, йолаларын өйрәнәләр. Халык – аваз иҗаты белән кызыксыналар, аңа хөрмәт белән карыйлар.



